**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ___________

«Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 октябрендәге 264 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Актаныш муниципаль районы бюджетында каралмаган җирле әһәмияттәге чараларны һәм көтелмәгән чыгымнарны финанслау мәсьәләсендә хокук нормаларын куллануның киң чикләрен яисә нигезсезлеген, вазыйфаи зат өчен коррупцион факторларны булдырмау максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 октябрендәге 264 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм 1 нче кушымтаны яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта нигезендә).
2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
____________ №____
1 нче кушымта

Актаныш районы Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатьләрне карау комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | |
| Сираева Л.Р. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; |
| Комиссия секретаре: | |
| Шәехова И.М. | Актаныш муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык секторы мөдире (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гарипов Р.И. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Нурлыева Л.Ф. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| Каюмова К.Р. | Актаныш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Хуҗәхмәтова Г.Ф. | Татарстан Республикасы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Шәрифҗанов И.И. | 103 янгын-коткару часте башлыгы (килешү буенча); |
| Нурлыев Н.Г. | Актаныш районы ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе (килешү буенча) |
| Разетдинова Ф.С. | «ТРО ВОИ» - «Татарстан инвалидлар җәмгыяте» рәисе (килешү буенча) |
| Гыйлаева М.З. | АМР Советының оештыру бүлеге башлыгы; |